# Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№2 (726) 28 январь 2021 ел (1442, Җөмәдел-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы


## ТЕЛЕҢ ӘЙТКӘННЕ КОЛАГЫҢ ИШЕТСЕН



Тел — адәм баласының күңелендә булган ачу, мәрхәмәт, йомшаклык, катылык кебек нәрсәләрне ачып бирүче; гыйлем вә әдәп һәм мәгърифәт кебек нәрсәләрне күрсәтүче булган әгъзасыдыр. Шуның өчен телегезне дөреслектән башка нәрсә өчен кузгатмагыз, тәрбиясез сүзләр сөйләмәгез. Кешенең сәламәтлеге телне саклауда икәнлекне онытмагыз! Арттырып сөйләмәгез, әмма һич ялган сөйләмәгез, гайбәт сөйләмәгез, сүз йөртмәгез, белмәгән нәрсәләрне сөйләргә керешмәгез, бер кеше сүз башлагач, тәмамламастан элек, гәрчә ахыры сезгә мәгълүм булса да — калдырып китмәгез! Бу исә — адәмчелектән мәхрүм булу галәмәтедер. Ялгыш сөйләвегез мәгълүм булганда, «хата әйттем» диюдән гарьләнмәгез. Сүзегезнең хата икәнлеге башкалар тарафыннан күрсәтелгәндә, хата түгеллеген яхшы белсәгез, каты сурәттә каршы тормыйча вә кычкырмыйча, әдәп белән җавап бирегез! Гомуми мәҗлесләрдә адәм тәнендә булган гаепләр хакында сөйләшмәгез, бер кеше хакында булган сүзне, башкалардан күчереп булса да, хикәят итмәгез, сөйләмәгез! Һичбер адәмгә ләгънәт итмәгез, каһәрле дога кылмагыз вә һичкемне сүкмәгез, вә һичкемне хурламагыз, яла якмагыз, хаҗәтегезне үтәгән вакытыгызда сөйләшмәгез, мөэмин вә башка кешеләрне куркытмагыз, өченче кеше бар икән, икегез яшерен сүз сөйләмәгез, усал эш артыннан йөрүчеләргә юл өйрәтмәгез, Аллаһы Тәгаләнең бер тел вә ике колак бирүдә, ишеткән нәрсәләрнең фәкать яртысын гына сөйләргә тиеш икәнлегенә ишарә барлыгын белми тормагыз!

**Риза ФӘХРЕДДИН** *("Әхлак гыйлеме"ннән)*

## ЧИТТӘН ТОРЫП УКЫЙБЫЗ

Туган тел елын йомгаклап һәм Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын каршылап, Татарстан мөфтияте һәм аның карамагында эшләүче "Хозур" нәшрият йорты зур яңа проект – татар телендә беренче онлайн-мәдрәсә булдырды. Җөмәдел-ахир аеның 7 нче көнендә нәзарәттә татар онлайн-мәдрәсәсе проекты тәүге тапкыр рәсми рәвештә журналистларга тәкъдим ителде. Аларның сорауларына Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры, Россиянең ислам мәгарифе советы рәисе Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин һәм Татарстан мөфтиенең мәгълүмати сәясәт буенча киңәшчесе, ТР МДН "Хозур" нәшрияты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, Кукмара имам-мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиев җавап бирде.

Беренче эш итеп Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Нәзарәт тарафыннан игълан ителгән Туган тел елы нәтиҗәләре – 2020 ел йомгаклары белән таныштырып үтте. "Елның иң зур казанышы – "Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә" хезмәтен бастыру һәм аны бар татар җәмәгатьчелегенә таныту булды. Туган тел елы кысаларында Татарстанның 100 мәчетендә татар теле курслары оештырылды. Моннан тыш, Алабугада "Ихсан" мәктәбе ачылды. Пандемия шартларында да татар милли традицияләрен торгызган "Яшь килен" проекты эшләде. 2020 елның соңгы казанышы – татар онлайн-мәдрәсәсе. Хәзер ислам дине нигезләрен читтән торып, интернет аша өйрәнеп булачак. Ул 100% татар телендә!" – дип билгеләп үтте мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Әнә шул рәвешле, планетаның төрле почмакларында яшәүче милләттәшләребезнең хәзер туган телдә Ислам нигезләре буенча гыйлем алу мөмкинлеге барлыкка килде. Онлайн-мәдрәсә medrese.tatar адресы буенча урнашкан белем бирү платформасында эшли. Мәдрәсәдә шулай ук iOS һәм Android базасындагы смартфоннар өчен эшләнгән махсус кушымта аша да "кереп" укып булачак. "Татар мәдрәсәсе" дип исемләнгән мобиль кушымтаны кесә телефонына Play Маркет һәм App Store-да бушлай күчереп алырга мөмкин.

Онлайн-мәдрәсә остазлары итеп республикабызның югары дини уку йортларында гыйлем алган һәм Диния Нәзарәтенең дини эшчәнлек алып барырга хокук бирүче шәһадәтнамәсенә ия булган имамнар җәлеп ителде.

Нәзарәт тәкъдим иткән беренче татар онлайн-мәдрәсә проекты хәзерге вакытта интернеттагы билгесез «шәех»ләрнең лекцияләренә, шикле булган видеодәресләргә бердәнбер альтернатива булып тора.

Беренче татар онлайн-мәдрәсәсенең эше буенча сораулар белән Инстаграмда махсус булдырылган @tatarmedrese аккаунтына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

## ЧАЛЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫ



14 гыйнвар көнне Чаллы шәһәре мөхтәсибәтендә имамнарның бу елда беренче җыелышы булып үтте. Көн тәртибендә 3 сорау каралды: 2020 елга хисап, ТР мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие һәм баш казыен сайлау һәм мәчетләрне паспортлау эшчәнлеген йомгаклау. Коръән аятьләре укып һәм дога кылып башланып киткән җыелышны Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин дәвам итте. Мәҗлеснең беренче өлешендә ул имамнарны 2020 елда башкарылган эшләр белән кыскача таныштырып үтте. Беренче сорауга кагылышлы чыгышның азагында узган ел эшчәнлеге канәгатьләнерлек дип билгеләнде. Мәҗлеснең икенче өлешендә Әлфәс хәзрәт ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең апрель аенда үтәчәк җыелышы һәм әлеге чарада ТР МДН җитәкчелеген яңадан сайлау булачагы турында әйтеп узды. Шул нисбәттән Чаллы шәһәре мөхтәсибәтеннән имам-мөхтәсиб тарафыннан Сәмигуллин Камил Искәндәр улын мөфти һәм Фазлыев Җәлил Вәсил улын баш казый кандидатлары итеп билгеләргә дигән тәкъдим булды һәм әлеге тәкъдим бертавыштан кабул ителде.

Җыелыш мәчетләрнең паспортларын яңарту эшчәнлеге турында фикер алышынганнан соң дога кылып тәмамланды.

***



24 гыйнвар көнне "Тәүбә" мәчете "Тукай" яр буенда урнашкан паркта мәхәллә яшьләре өчен йөгерү чарасы уздырды. Бәйгегә теркәлү иртәнге тугызынчы яртыда башланды, сәгать 9 да чараны кыскача вәгазь белән ачып җибәрү булды. Катнашучылар, яшьләренә карап, 3 төркемгә бүленде. Беренчеләрдән булып йөгерешне кечкенәләр (5-9 яшь) башлап җибәрде. Алар 500 метр озынлыктагы арада үзләренең көчләрен сынады. Соңрак яшүсмерләр (9-14 яшь) 1 км, алардан соң 14 яшьтән өлкәнрәкләр 2 км һәм 5 км озынлыктагы дистанцияне йөгерде. Чара тәмле чәй һәм пылау өстәле янында тәмамланды.

**Нияз ГАЗИЗОВ**

# МӘЧЕТТӘ ЯЛАНАЯК ҺӘМ БАШКА ТҮБӘТӘЙ КИМИ НАМАЗ УКУНЫҢ МӘКРУҺЛЫГЫ

***Аллаһы сөбханәһү вә тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: 29.45. «Ий Мөхәммәд галәйһиссәләм, Коръәннән вәхи ителгән аятьләрне укы һәм намаз укы, чынлыкта намаз фәхеш эштән дә, ярамаган эшләрдән дә намаз укучыны тыя. Намаз, әлбәттә, Аллаһ зикерләренең иң зурысы, Аллаһ сезнең ни эшләгәннәрегезне белә».***

Бу аяти-кәримәдән күргәнебезчә, намаз кешене төрле бозыклыклардан, фәхеш эшләрдән тыя. Әмма ни өчендер шул ук вакытта мәчетләрдә намаз укырга килгән мөселманнар арасында еш кына намазга кагылышлы фетнәләр чыгып тора. Бу фетнәләрнең күпчелеге намазны яланаяк һәм яланбаш укуга кагыла. Бүген күп кенә яшьләр җылы якларда, Ислам илләрендә укып белем алып кайталар һәм андагы тәртипләрне монда да кертә башлыйлар. Алар Ислам динендә официаль рәвештә генә 1100 еллык тарихы булган, бабаларыбыздан калган гореф-гадәтләрне юкка чыгарырга, наданлык дип аңлатырга тырышалар. Без, урыс елъязмаларында күрсәтелгәнчә, «читекле» халык. Рим-католик чиркәве миссионеры француз Вильгельм Де-Рубрук Рим папасына безнең болгар бабаларыбызны түбәндәгечә бәяләп хисап бирә: «Бу болгарлар Мөхәммәтнең кануннарына башка бөтен халыкларга караганда да ныграк ябышканнар». Без динебез, иманыбыз көчле булганга күрә генә халык буларак сакланып кала алганбыз. Сүз дә юк, бүген безнең бабаларыбызның мирасы үзебездә язма әсбаплар буларак сакланмаган, әмма без аларның хезмәтләрен ислам дәүләтләре китапханәләреннән табабыз, аларның гыйлемнәрен күреп гаҗәпләнәбез һәм горурланабыз.

Без «читекле» халык, без намаз укыганда гына түгел, хәтта көндәлек тормышта да яланаяк, яланбаш йөрмәгәнбез һәм безнең бу рәвештә киенүебез, тормыш итүебез сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәднең (салла-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) яшәү рәвеше.

Әбү Сәед әл-Хөдрий р.г. сөйләп калдырган: «Аллаһының Расүле (салла-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) үзенең сәхәбәләре белән намаз укыган вакытта, аяк киемен салып, үзенең сул ягына куйган. Һәм, моны башка кешеләр күргәч, алар да үз аяк киемнәрен салып куйганнар. Аллаһының Расүле (салла-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә), намаз укып бетергәч: «Сез нигә аяк киемнәрен салдыгыз?», - дип алардан сораган. Алар аңа: «Без синең аяк киемеңне салганыңны күрдек тә, үзебезнекен дә салып куйдык», - дип җавап биргәннәр. Һәм "Аллаһының Расүле (салла-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә): «Чынлап та, Җәбраил (галәйһиссәлам) фәрештә минем янга килеп, анда пычрак бар дип әйткән иде», - дигән. Аннан соң: «Әгәр дә кем дә булса мәчеткә килә икән, аягына кигән әйберендә пычрак яки шакшылык бармы-юкмы икәнен карасын, әгәр дә аяк киемендә пычрак һәм шакшылык бар икән, аны тазартсын һәм аның белән намаз укысын», - дип әйткән» .

Күргәнебезчә, Аллаһының Расүленең (салла-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) яланаяк намаз укуының сәбәбе – ул аяк киемендә пычрак, ягъни нәҗес булуы гына сәбәп булган. Ә үзенең сәхәбәләренә ул аякка киелгән әйбернең чиста булу шарты белән аяк киемнәрен салмыйча гына намаз укырга тәкъдим иткән.

Чынлап та, яһүдиләрнең гыйбадәт кылуының нигезе – яланаяк намаз уку. Аларның яланаяк укуларының сәбәбен без «Та һа» сүрәсенең 12 нче аятендә Аллаһы Тәгаләнең Муса галәйһиссәләмгә булган боерыгында күрәбез: 20.12. «(Ий Муса!) Синең Раббың, әлбәттә, Минмен, башмакларыңны сал, чөнки син Тува исемле мөкатдәс чокырдасың».

Бу боеру мөселманнарга түгел, бәлки яһүдләргә генә кагыла. Ә Йаглә бине Шаддад бине Аус үзенең әтисеннән риваять кылган хәдистә исә Пәйгамбәребез (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) мөселманнарга боерып әйтә: «Яһүдиләргә кире сен эшләгез. Чөнки алар, чынлап та, үзләренең сандалый һәм читекләрендә намаз укымыйлар» .

Бу хәдистән күргәнебезчә, Пәйгамбәребез (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) яланаяк намаз укуны яһүдләргә охшарга тырышу белән тиңләгән һәм үзенең сәхәбәләрен яланаяк намаз укудан тыйган.

Яланаяк гыйбадәт кылу – яһүдиләр үзенчәлеге. Мөхәммәд (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) өммәтенә исә, аякларга киеп намаз уку тәкъдим ителгән. Ул калын, нык аяк киемеме, әллә инде юка оекларммы, моның әһәмияте юк. Фәкать аяк киеме чиста, пакь булырга тиеш. Безне яһүди һәм христианнардан аерып тора торган бу өстенлек Мөхәммәд өммәтенә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бүләк. Моны шулай кабул итәргә кирәк. Өстәвенә, безнең сөекле Пәйгамбәребез (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) үзенең күп кенә хәдисләрендә безне яһүди һәм христианнардан аерылып торырга да өнди.

Ибне Гомәрдән (радый Аллаһу ганһү) риваять кылына, Аллаһының Расүле (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) әйткән: «Кем нииндир халыкка охшарга тырышса, ул – шулардан саналыр» .

Пәйгамбәребезнең (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) сөннәтләренә буйсынып, яһүдиләрдән һәм насаралардан аерылып торыр өчен, без аякларыбызга оекбаш һәм читек кебек аяк киемнәре киеп кенә намаз укырга тырышабыз. Хәтта аякка оекбаш, читек, яисә башка берәр нәрсә киеп укуның тиешлеге турында алда әйтеп кителгән дәлилләр булмаса да, без барыбер, Россия мәчетләрендә аякларыбызга оеклар киеп намаз укырга тиешбез. Әлхәмдүлилләһ, бүгенге көндә мәчетләребезгә намазларга йөрүчеләр арасында мөселман табиблар да бар. Без алар белән дә киңәшләшәбез һәм алар мәчетләрдә гөмбәчек авырулары таралу ихтималлыгы турында безне кисәтәләр. Аяк киеме белән намаз уку, медицина күзлегеннән караганда, гыйбадәт белән бәйләмәгән очракта да, безнең якларда, ягъни төньяк җирлегендә мәҗбүри булып тора. Бу мәсьәләдә бернинди бәхәскә дә урын калмый. Безнең мәчетләребез – җәмәгать урыннары, динебез һәрберебездән чисталык таләп итә, шуңа да, анда чисталык саклау һәм гыйбадәт кылу өчен төрле йогышлы авырулардан хәвефсез шартлар тудыру – безнең бурычыбыз. Бу әйтелгәннәргә җиңел карага кирәк түгел, мәчетләрдә гөмбәчек авырулары йоктыру очраклары – чынлап та билгеле.

Аякка киеп намаз укуда тагын бер фетнәле мәсьәлә бар – ул аяк киеменә мәсех кылу. Хәдисләрдә Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең «җәураб»ка мәсех кылуы турында әйтелә. Яшьләр «җәураб»ны бездә җәй көне киеп йөри торган юка оекбаш (носки) дип юка оекбашларга мәсех кылып намаз укыйлар. Әмма гарәпчәдәге «җәураб» бездәге юка оекбаш (носки) түгел, бәлки калын йоннан тукылып аякның башыннан алып балтыргә кадәр каплый торган булган. Калын булу сәбәпле аның үзен генә киеп шактый гына йөрергә мөмкин булган, ягъни бездәге киез итеккә тиң, бөгелми, сынмый, аякны юлдагы төрле чәнечкеләрдән, ташлардан саклый торган аяк киеме булган (аңлатмасы әл-Камус әл-Фикһий, әл-Ифсах фи Фикһ әл-Лүгъа һ.б. бирелә).

Әбү Давыдта (159), Тирмизидә (327), ибн Мәҗәһтә (559) китерелгән хәдисләрдә Пәйгамбәребезнең (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) «җәураб»ка мәсех кылуы турында әйтелсә дә, алда аңлатып кителгәнчә, «җәураб» юка оекбаш түгел һәм, күпчелек галимнәр аңлатканча, юка оекбашларга мәсех кылынмый. Димәк, юка оекбашларга мәсех кылып укыган намаз дөрес саналмый, әгәр имам шул рәвешчә намаз укыса, оеп укучыларның да намазлары дөрес булмаячак.

Алда әйтелгәннәрдән чыгып без шундый нәтиҗәгә киләбез: безнең аякка киеп һәм фәкать читек яисә читек кебек су үткәрми һәм аны киеп җәяү юлда йөреп була торган аяк киеменә генә мәсех кылып намаз укуларыбыз сөннәткә муафикъ рәвештә башкарыла. Ә инде безне тәнкыйтьләүчеләргә килгәндә, аларның тәнкыйть сүзләре аларның үзләренең наданлыкларын күрсәтүче бер дәлил булып тора.

Безнең гыйбадәтебез яһүд һәм насара дин әһелләренең гыйбадәтеннән яланаяк укымау белән генә түгел, бәлки яланбаш укымау белән дә аерылып тора. Чөнки пәйгамбәребез (салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмә) һәрвакыт башына чалма киеп кенә намаз укыган. Сәхәбәләр аны бер тапкыр гына чалмасыз көе күргәннәр. Анысы да чалмасын юу сәбәпле генә булган. Ә хаклыкта бу да безнең гыйбадәтебезне яһүд һәм насараларның гыйбадәтеннән аерып тора торган бер билге булып тора. Насараларның чиркәүгә кергәндә баш киемен мәҗбүри салыргә тиешлеге турында үз гомерендә бер генә тапкыр булса да чиркәүгә кергән теләсә кайсы христиан кешесе раслар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: 7.31.«Ий Адәм балалары! Һәр мәчеттә намазга зиннәтле киемнәрегезне киегез...»

Ибне Гомәрдә риваять ителгән бер хәдистә пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Әгәр берәрегез намаз укырга теләсә, гаурәтләрен каплап, матур киемнәрен кисен. Хакыйкатьтә, Аллаһ газзә вә җәллә өчен зиннәтләнү башкалар өчен зиннәтләнүдән хаклырак» .

Бу әйтелгәннәрдән чыгып күпчелек галимнәр баш киеме киюне, ягъни башны каплауны зиннәткә керә дип әйтәләр. Ә инде башка кимичә дә намаз укырга була дип әйтүчеләр үз дәлилләрендә зәгыйфь хәдисләр кулланалар һәм мин алар турында әйтеп тә тормыйм.

Алда әйтеп кителгәнчә, безнең бабайларны наданлыкта гаепләү дөреслеккә туры килми һәм бу аларга карата яла ягу була, ягъни зур гөнаһлардан санала. Ничә гасырлар империя изүе астында булып, чукындырып чукынмаган бабаларыбыздан калган гореф-гадәтләр фәкать сөннәтләргә генә нигезләнгән булуына без шәригатебезне ныграк өйрәнгән саен ныграк ышанабыз гына. Бу ышаныч бездә фәкать горурлык хисе генә уята.

Әлхәмдүлилләһ, без – Ислам динендә 1100 еллык тарихы булган татар халкы. Без үзебезнең мөселманлыгыбыз белән мактанабыз, горурланабыз. Без аңларга тиешбез: мөселман кеше Аллаһы Тәгаләнең боерыкларын үтәргә, пәйгамбәренең сөннәтләренә иярергә тиеш. Намаз – безгә йөкләтелгән иң зур гыйбадәт, Раббыбыз белән иң якын вакытыбыз, иң якын урыныбыз. Бу гыйбадәтне үтәгәндә без аның фарызларына һәм вәҗибләренә генә түгел, бәлки сөннәтләренә һәм мөстәхәбләренә дә, кыскасы, үзебез үти алырдай барысына да игътибарлы булырга тиешбез. Тышкы кыяфәтебез – һичшиксез, без үти ала торганнарыннан һәм аны мөмкин кадәр җиренә җиткереп үтәргә тырышырга кирәк. Эчке халәтебез – кешегә күренми торганы, шайтан төрле уй-фикерләр белән читкә алып китә торганы, хәтта намаз бозылыр дәрәҗәгә җиткерә торганы. Тышкы кыяфәтебез җитәрлек дәрәҗәдә ныклы булмаса, шайтанга эчке халәтебезгә тәэсир итү җиңелрәк була. Шуңа күрә, күңелдә булса шул җитә, дип тәкәбберләнеп йөрергә кирәк түгел.

Аллаһы Тәгалә һәммәләребезне дә үзенең кушканнарын үти һәм тыйганнарыннан тыела торган, пәйгамбәренең сөннәтләренә ияра торган сөекле колларыннан насыйп кылсын.

**Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,**
*Чаллының «Ак мәчет» имам-хатыйбы*

## “ӘЙБӘТ ГАЙБӘТ” БУЛАМЫ?

Матбугат ирегә килгәч, кайбер газеталар “Әйбәт гайбәт” дигән рубрикаларда күренекле кешеләрнең (бигрәк тә артистларның) шәхси тормышлары турында төрле язмалар бастыра башлады. Гайбәт әйбәт буламы? Нәрсә ул гайбәт? Бу начар гадәттән ничек котылырга, балаларга гайбәтнең начар икәнлеген ничек итеп, нинди юллар белән төшендерергә? Сүзлекләргә мөрәҗәгать итсәк: “Гайбәт – уйдырма фактларга нигезләнгән сүз (хәбәр)”. Бу билгеләмәдән уйдырма фактларга нигезләнгән, ягъни дөрес булмаган нәрсә турында сөйләсәң, гайбәт була дигән фикер килеп чыга. Шундый фикер безнең татар халкы арасында да нык таралган. “Ник ул кеше турында сөйлисең?” – дип сорау бирсәң, “мин бит дөресен сөйлим”, – дип җавап кайтаралар. Дини күзлектән караганда, гайбәт – зур гөнаһ, чөнки гайбәт кешеләр арасында дошманлык китереп чыгара, ә ислам дине дуслык, тынычлык, иминлеккә өнди.

Беркөнне Пәйгамбәребез галәйһиссәләм сәхәбәләреннән сораган: “Гайбәт нәрсә ул, беләсезме?” Иптәшләре: “Аллаһ вә аның Илчесе белер”, – дигәннәр. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: “Дин кардәшенең хушына килмәгән сүзләрне аның артында (ягъни ул ишетмәгәндә) сөйләүдер”, – дигән. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм сәхәбәләренең: “Әгәр кардәшләребезне яманлавыбыз дөрес булса, сөйләргә ярыймы?” – дигән соравына : “Әгәр сөйләгән сүзләрең дөрес булса, гайбәт сөйләгән булырсың. Сөйләгән сүзләрең дөреслеккә туры килмәсә, яла яккан булырсың”, – дип җавап биргән. “Хуҗурәт” сүрәсенең уникенче аятендә түбәндәге юллар бар: “...кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез вә бәгъзегез бәгъзегезне гайбәт кылмасын! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме?”. Әбү Һөрәйрә разыяллаһу ганһү сүзләреннән риваять ителә: “Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте: “Кем Аллаһыга һәм Кыямәт көненә иман китерә, хәерлене сөйләсен яисә дәшмәсен”.

Мөгаз разыяллаһу ганһү сорый: “Әй Аллаһының илчесе, сөйләгән нәрсәләр бездән соралачакмыни?” – һәм (Пәйгамбәр галәйһиссәләм) кычкырып җибәрде: “Кешеләрне утка йөзләре белән яла ягып сөйләгән сүзләреннән башка тагын нәрсә дә булса өчен ыргытылырлармы әллә?!” Әнәс разыяллаһу ганһү сүзләреннән риваять ителә, Аллаһының илчесе әйтте: ”Мин күккә күтәрелгәч, үзләренең битләрен һәм күкрәкләрен тырный торган бакыр тырнаклы кешеләр янынннан үтеп киттем һәм мин: “Кем алар, әй Җәбраил?” – дип сорадым Ул әйтте: “ Бу кешеләрнең итләрен ашаучылар (ягъни гайбәтчеләр) һәм аларны хур итүчеләр”. Әбү Һөрәйрә разыяллаһу ганһү сүзләреннән риваять ителә, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте: “Һәр мөселман өчен (башка) мөселманның гомере, намусы һәм малы кагылгысыз (булырга тиеш)».

Коръәндә “Һүмәзә” (“Сүз йөртүче”) дигән, гайбәтчеләргә кагылышлы махсус сүрә дә бар: “Үкенеч һәм һәлакәтлектер һәрбер сүз йөртүче гайбәтчегә”. Шушы ук фикер “Каләм” сүрәсенең 10-11 аятьләрендә дә бар: ”Итагать итмә күп ант итүче җиңел гакыллы ялганчыга. Кешене мәсхәрәләп гайбәт сөйләүче, сүз йөртүчегә”. Әнәс разыяллаһу ганһү сүзләреннән риваять ителә, Аллаһының Илчесе галәйһиссәләм әйтте: “Гайбәтче җәннәткә кермәс”.

Үзең гайбәт сөйләмәсәң дә, гайбәт сөйләүченең янәшәсендә калган очракларда нәрсә эшләргә? Бу турыда да Коръән аятьләре һәм хәдисләр бар. Мәсәлән, “Касас” сүрәсенең 55 нче аятендә мөэминнәр турында: “...яман буш сүз ишетсәләр, алардан читләшәләр...” – дип әйтелә. “Мүэминүн” сүрәсенең 36 аятендә шундый юллар бар: “Вә дәлилең, белемең булмаган нәрсәгә иярмә, ягъни дәлилсез гамәл дә кылма, хөкем дә итмә, фәтва дә бирмә! Аллаһ биргән колак, күз, күңел – боларның һәрберсеннән кыямәт көнне сорау булыр, аларны саваплы урыннарга гына кулланыгыз!” Аллаһы Тәгалә шулай ук әйтте: “Әгәр аятьләребезне яманлап сөйләүчеләрне күрсәң, хәтта башка сүзгә күчкәннәренә чаклы алар янында торма, кит! Вә әмма алардан киселү хакындагы Аллаһ хөкемен шайтан сиңа оныттырса, хәтереңә төшү белән кит, залим кавемнәр янында торма”. Әбү Дардә разыяллаһу ганһү сүзләреннән риваять ителә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: “Кем кардәшенең намусын яклый, Аллаһ аны Кыямәт көнендә уттан саклар”.

Шулай да җәмгыятьтәге гаделсезлекләрдән, кайбер кешеләрнең золымыннан котылу юлы бармы, ягъни гайбәт нигездә хәрәм булса да, аның хәләл очраклары күзәтеләме? Гайбәт дөрес һәм шәригатькә каршы килми торган максатка ирешү өчен генә, башка юл белән аңа ирешү мөмкин булмаган очракта рөхсәт ителә. Дин галимнәре, хәдисләргә таянып, аның алты сәбәбен күрсәтәләр:

Беренчесе – шикаять кылу. Золымлыкка очраган кешегә хөкемдарга, казыйга һәм хакимлеккә ия булган яки аның һәм залим арасында гаделлек белән хөкем итә ала торган башкаларга шикаять бирергә рөхсәт ителә, һәм бу очракта золымлыкка очраган кеше : “Фәлән миңа золымлык кылды”, – дип әйтә ала.

Икенчесе – тыелганны үзгәртү яки итагать кылмаучыны тугры юлга кайтару максаты белән ярдәм сорау. Бу очракта кеше тыелганны бетерү эшендә көченә өметләнгән икенче кешегә түбәндәгене әйтә ала: “Фәлән шулай эшли, аны моннан тыеп кал”.

**Рәзинә МӨХИЯРОВА,** *Чаллының «Ак мәчет» мөгаллимәсе*

*(Ахыры 4 нче биттә)*

## ӘДӘБИ СҮЗ

***Айрат СУФИЯНОВ***

### *НӘРСӘ ӘЙТЕРБЕЗ?*

*Сәгадәткә юл күрсәтми*
*Ачылмаган киңлекләр.*
*Хакыйкатьне танып белгән,*
*Бездән ерак яшерелгән*
*Күпкырлы мөмкинлекләр.*
*Гөнаһка тарткан чикләрне*
*Әллә узып киткәнбез?*
*Күпме асыл кыйммәтләрне*
*Гамьсез җуйдык икән без?*
*Кайда чыдамлык, итагать,*
*Ник килде түземсезлек?*
*Аллаһ белән каршылыкта*
*Яуланмый үлемсезлек…*
*Сират күпере дөньяда –*
*Тәкәббер үзсүзлелек.*
*Бары иман, ахирәткә*
*Күчәчәк изге милек.*
*Аллаһ безгә юкка түгел*
*Акыл биргән, җан өргән.*
*...Дөнья – сөрген, безне аңа*
*Сынар өчен җибәргән…*
*Шуңадыр, елап туганбыз,*
*Ни көткәнен тоепмы?*
*...Аллаһка кабат кайтырбыз*
*Җан яшьләрен коепмы?..*
*Канлы болытлар аша да,*
*Могҗиза, кояш чыга.*
*...Акланып, нәрсә әйтербез*
*Безне яратучыга?..*

## *Колак салсаң, үкенмәссең*

**Кешеләр шул телләре белән кылган гамәлләре өчен йөзләре белән җәһәннәмгә ыргытылырлар*

**Бер мөэмин икенче мөэминнең көзгесе*

**Гайбәт сөйләүче белән аны тыңлаучының гөнаһлары уртак*

**Кем дә кем башка кешенең гаебен белдертмәсә, ахирәттә аның гаепләрен белдертмәм*

**Акылы кысканың теле озын*

**Аягы пычрак — өй пычратыр, теле пычрак — кеше пычратыр*

**Бирәүнең кулы эшли, икенченең теле эшли*

**Дөньяда иң татлы нәрсә дә — тел, иң ачы нәрсә дә — тел*

## КУЛЛАНЫРГАМЫ, КУЛЛАНМАСКАМЫ?

***Nike компаниясе әзерләп чыгарган аяк киемнәрен һәм киемнәрне киеп йөрергә ярамый, чөнки “nike” сүзе мәҗүсилектә илаһ исеме дип ишеттем. Бу дөресме?***

Спорт киемнәре бренды атамасы булган “Найк” сүзе, чыннан да, грекларда җиңү алиһәсе Ники исеменә барып тоташа. Күп кенә брендлар һәм аларның логотиплары борынгы мифология һәм мәҗүсилек карашлары белән сугарылган. Мисал өчен, Мазда автомобиле зороастризм илаһы Ахур Мазда исеменнән алынган, бу турыда компаниянең сайтында да хәбәр ителә. Старбакс компаниясенең логотибы Синера дип аталган мифологик сурәткә кайтып кала. Мондый мисаллар шактый. Хәтта инглиз телендәге атна исемнәре дә мифологик һәм мәҗүси тамырларга тоташа: Thursday – Тора көне, Saturday – Сатурн көне. Хәтта күп кенә рус сүзләренең тамырлары мәҗүсилеккә бәйле: “врач”, мәсәлән, сихерче, күрәзәче дигән мәгънәләрне белдерүче тамырдан ясалган.

Брендның товарын мөселманнар өчен рөхсәт ителгән-ителмәгән булу мәсьәләсенә килгәндә, без сүзнең заманча, бүгенге мәгънәсенә игътибар итәргә тиеш. Әйтик, рус телендәге “обожать” сүзе элек нәрсәнедер Аллаһка тиңләүне белдерсә, хәзер аның бу мәгънәсе юкка чыккан. Бу мәгънә сүзлекләрдә дә иске мәгънә буларак теркәлгән. Әгәр кеше сүзгә Аллаһка тиңләштерү мәгънәсен салмый икән, аны куллануда бернинди зарар юк. Даруль-ифта Мәхмүдия (Дурбан, Көньяк Африка) хәнәфи галимнәре дә шундый ук аваздаш фәтва бирә: “Күп кенә гомумкулланылышта булган сүзләр, мәсәлән, ай атамалары (инглиз телендә), атна исемнәре, планета һ.б. төрле атамалар грек яисә рим мифологиясенә барып тоташа. Әмма аларны бүген мәгънәсен исәпкә алмыйча кулланалар. Шунлыктан, бу сүзләрне кулланырга ярый” (№ 39105 фәтвасы). Шулай итеп, Nike киемнәрен киюне мөселманнар өчен тыйган кешеләрчә фикерләсәк, ширеккә төшмәс өчен, телдән иң элек мәгънәсе буенча мәҗүси булган барлык сүзләрне аерып алырга (ә бу мөмкин дә түгел), аннары аларны кулланылыштан алырга кирәк.

Кемнәрдер, брендларның исемнәре мифологиягә тоташуын сәбәп итеп, ул брендлар белән кулланмаска (Тойота машинасында йөрмәскә, айфоннар йөртмәскә, старбакста кофе эчүдән баш тартырга) мөмкин, әмма Аллаһ исеменнән бу тыюларны кертергә ярамый. Кайберәүләр, үзләренең шәхси тойгыларын фикһ хөкемнәре белән бутыйлар, алай булырга тиеш түгел. Бүгенге көндә мөселманнарның күп проблемалары төгәл гыйлеме, махсус әзерлеге булмыйча торып “фәтвалар бирергә” ашыгучылар аркасында барлыкка килә . Әмма фикһнең хөкемнәрен — хәләл һәм хәрәм темалары буенча — шәхси тоемлау, “миңа шулай тоела” дигән фаразлар белән бутарга ярамый. Андый чакта наданлык һәм вәсвәсәгә юл ачылачак. Ә Аллаһ яхшырак белүче!

*(ТР МДН фәтваларыннан)*

## АКЫЛЫҢА БУЙСЫН

Бүгенге көндә бик күп истәлекле даталар, бәйрәмнәр бар. Без бер датадан икенчесенә, бер бәйрәмнән икенче бәйрәмгә әзерләнеп, бәйрәм итеп гомер үткәрәбез. Эшләргә, гамәл кылырга вакыт калмый. Бәйрәм дә итәргә кирәк, тик акыл белән, тиешле кысадан чыкмыйча. Адәм баласының бөтен гомере — акыл белән нәфес көрәше. Гомерең хаталар һәм ялгышлар җыентыгына әйләнмәсен дисәң, акылыңны намаз белән, нәфесеңне ураза белән тәрбиялә. Акылың да, нәфесең дә тәртипсез икән, беркем дә, бернинди оешма да синнән тәртипле кеше ясый алмый инде. Димәк, җәмгыятьтә дә тәртип була алмый, чөнки күп вакыт үзләре дә шул нәфес коллары булып кала бирәләр. Без кешечә яшәсен өчен Аллаһ Раббыбыз дин биргән, Коръән иңдергән, үзенең пәйгамбәрләрен җибәргән. Гомеребез, бәйрәмнәребез, яшәешебез хәрәмнәрсез, Аллаһ риза булырлык итеп үтәргә тиеш.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,** *Татарстанның баш казые*

## “ӘЙБӘТ ГАЙБӘТ” БУЛАМЫ?

(Ахыры. Башы 3 нче биттә)

Өченчесе – нинди дә булса дини хокук мәсьәләсе буенча карар (фәтвә) чыгаруны сорап мөрәҗәгать итү; кеше мөфтигә шундый сүзләр әйтә ала: “Миңа шул нәрсәдә этием (яки абыем, ирем) золымлык кылды, ләкин аның моңа хакы бармы? Һәм ничек миңа хакым булган нәрсәгә ирешергә һәм золымлыктан котылырга?”, яки башка шундый сүзләр.

Дүртенчесе – мөселманнарны начарлыктан кисәтү һәм аларга яхшы киңәш бирү. Бу берничә очракта рөхсәт ителә, шул исәптән: сүзләрендә шикләнерлек нигез булган риваятьчеләрне һәм шаһитләрне кире кагарга кирәккәндә, бу барлык мөселманнарның килешкән фикере буенча рөхсәт ителгәнгә түгел, ә зарурият очрагында ваҗиб та булып тора; кемгә булса да никах юлы белән туганлык мөнәсәбәтләренә керергәме, яки аның белән хезмәттәшлек итәргәме, яки саклау өчен нәрсәне дә булса ышандырыргамы, яки аның белән ниндидер башка эшләр алып барыргамы, яки аның белән күрше булып яшәргәме дип, киңәш сорарга кирәккәндә, киңәшче аннан сорала торган кеше турында бернәрсәне дә яшермәскә бурычлы, киресенчә, яхшы киңәш бирергә теләп, аның барлык кимчелекләрен әйтергә тиеш.

Бишенчесе – кем булса да җитешсезлеккә ачыктан-ачык бирелеп китсә яки бидгать гамәлләр кылса, мәсәлән, әгәр ачыктан-ачык хәмер эчсә, кешеләргә һәртөрле киртәләр кылса, хокуксыз рәвештә сәүдә салымнары алса, башкаларның малын үзенә алса яки башка дөрес булмаган гамәлләр кылса, мондый очракларда ачыктан-ачык кешенең кылганнары турында әйтергә рөхсәт ителә, ләкин аның башка кимчелекләрен әйтү тыела.

Алтынчысы – күзаллау; әгәр кеше нинди дә булса кушамат, мәсәлән, Аксак, Чукрак, Сукыр, Кылый яки башка нинди дә булса кушаматы белән билгеле булса, аны болай атарга рөхсәт ителә, ләкин кушамат белән мөрәҗәгать итүнең максаты кешенең дәрәҗәсен төшерү генә булган очракта, боларны эшләү тыела, шуңа күрә, әгәр аны ничек тә булса башкача атап була икән, хәерлерәк булыр.

Гайбәтнең, сүз йөртүнең начар гадәт булуын безнең халкыбыз күптән аңлаган, бу турыда бик күп мәкальләр иҗат ителгән. Аларның кайберләре түбәндәгеләр:

1) Биткә әйткәннең зәһәре юк. 2) Биткә әйткәннән читтә әйткән яман. 3) Гаепсез кол булмас, Алла колының гаебен йөзенә ормас. 4) Кешене артында сөйләмә, алдында сөйлә. 5) Кешенең алдында сөйләргә ярамаган сүзне артында да сөйләмә. 6) Кешенең гаебен сизсәң, үзенә генә әйт. Дөньяны җил бозар, кеше арасын сүз бозар. 7) Сүз иясе белән йөрми. 8) Сүз иясеннән алда килеп җитә. 9) Сүзнең иясе юк, диңгезнең буасы юк .

Балаларга да кече яшьтән гайбәтнең начар икәнлеген төшендереп, иптәшләренең кире якларын сөйләүдән тыярга кирәк. Киресенчә, балага аралашкан иптәшләренең уңай якларын күрергә өйрәтергә тиешбез.Әгәр бала иптәшләренең килешмәгән сыйфатларын күрә икән, ул бу турыда иптәшен рәнҗетми, үпкәләтми генә үзенә әйтсен. Баланы яхшылыкка өйрәтсәк, ул шул тәрбия белән үсәчәк һәм ике дөньяда да бәхетле булачак. Аның әҗере үзен өйрәткән, тәрбияләгән кешеләргә дә барып ирешәчәк. Әгәр баланы начар нәрсәгә өйрәтсәләр, моның гөнаһы үзенә дә, үзен тәрбияләргә тиешле булган кешеләргә дә төшәчәк. Аллаһы Тәгалә “Тәхрим” (“Тыю”) сүрәсенең алтынчы аятендә әйткән: “Ий, мөэминнәр, үзегезне һәм өй җәмәгатегезне җәһәннәм утыннан саклагыз...” [4, б. 560].

Ут газабы – җәһәннәмгә кермәс өчен, сөйләгән сүзләребез гайбәт булмыйча, Аллаһы Тәгалә разый булырдай сүзләр булып, аның рәхмәтенә ирешергә тырышыйк, балаларыбызны да, оныкларыбызны да шуңа өйрәтик!

**Рәзинә МӨХИЯРОВА,** *Чаллының “Ак мәчет” мөгаллимәсе*

*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ



Бишек җырын җырлап, әни
Сеңелемне йоклата.
Ул җырны өйрәнгән булган
Мин бәбәй булган чакта.
Күңелемә сеңгән шул көй
Аңламаган килеш тә.
Әйтелгән изге китапта:
“Әниеңне рәнҗетмә!”

Вагоннары бик уңайлы –
Метроны мин яратам.
“Тагын төшик метрога”, - дип,
Әнине аптыратам.
Ә борынгы заманнарда
Атлар белән йөргәннәр.
Заман һаман яхшыра ул
Аллаһ рөхсәте белән.



*Саулыгым-байлыгым*

## КӘБЕСТӘ



Кәбестә җиңел үзләштерелә, ул файдалы микроэлементларга, витаминнарга бик бай. Аның согын йөрәк һәм ашказаны авырулары булганда эчәләр. Яфраклы кәбестә составында магний, хром һәм фолий кислотасы бар. Шуңа да ул тынычландыру, йокысызлыктан коткару көченә ия. Яфраклы кәбестәдән салат ясау бик җайлы. Юып, токмач сыман турап, тәменчә тоз, бер чеметем шикәр комы, борыч, лимон суты, үсемлек мае салып бутарга һәм бер 10-15 минутка калдырырга кирәк. Бу арада кәбестәнең суты чыга, йомшарып китә. Кыргычтан уып, чи кишер салганда, витаминнар тагын да күбәя төшәр. Брокколи кәбестәсе соңгы чорда бигрәк тә популяр. Аның составында күкрәк яман шешен кисәтүче матдә табылган. Аксым, каротин, минераль тозлар һәм витаминнар чыганагы да ул. Кәбестә күбесенчә судан тора, аз калорияле яшелчә булып санала, шуңа да аны ябыгырга теләүчеләр яратып ашый. Ул сидек юлларын чистарта, йөрәк-кан тамырлары авырулары вакытында файдалы. Яфракларын буыннар ялкынсынганда, бәрелгән урынга куялар. Шикәр диабетлы кешеләргә дә бу яшелчәне ашау яхшы. Ул кандагы глюкоза күләмен киметә. Калкансыман биз авырулары вакытында кәбестә зыянлы булырга мөмкин. Шулай ук ашказаны җәрәхәтләре булганда, чамасын белеп кенә ашарга киңәш ителә.

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР
Баш мөхәррир
Муллагалиева А. Г.
Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45
* * *
Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.
Электрон хатлар өчен:
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

Бу санның тиражы: 700
Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *
Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир, типография һәм редакция адресы:
423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
28 январь 16 сәг.
фактта 28 январь 16 сәг.
Бәясе ирекле